ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 19 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацындагы нигезләмәнең гамәлдә булуы түбәндәгеләргә кагылмый дип билгеләргә:

1) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларга;

2) хәрби хезмәткәрләр, ихтыярый формированиедә катнашу турында контракт төзегән затлар, Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт үтүче затлар арасыннан булган махсус хәрби операциядә катнашучы затларга;

3) әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән затларның ата-аналарына, хатынына яисә иренә, балигъ булмаган балаларына.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 29 апрель
№ 27-ТРЗ